СОВЕТ МАЙДАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ МӘЙДАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

03.04.2024 | с. Майдан | № 42-221

«Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлегенең Мәйдан авылында 17.11. 2023 ел гражданнар җыенының № 3 карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү 22.11.2013 ел № 90 тәртибенең 2 пункты (29.11.2023 ел № 1532 редакциясендә) нигезендә

Югары Ослан муниципаль районының
Мәйдан авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. «Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлегенең Мәйдан авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 декабрендәге 3 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 13 апреленә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:
«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлегенең Мәйдан авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 17.11.2023 ел № 3 карарына үзгәрешләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә сез рөхсәт бирәсезме:
- Мәйдан авылы чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын Мәйдан авылы территориясенең бер өлешендә урамнар буйлап уздырырга:

Яшьләр урамы, 1 нче йорт янында - 10.00 сәгатьтә,
Кооперативная урамы, 14 нче йорт янында - 11.00 сәгатьтә
Киров урамы, 92 нче йорт янында - 12.00 сәгатьтә .

4. Гражданнар җыенын оештыручы - Мәйдан авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге башлыгы В.В.Михеев